Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге Советы Карары

«30» октябрь 2020ел № 6

**11.11.2019 ел № 117 Комыргуҗа авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә Комыргуҗа авыл җирлеге Советы карар итте:

1 .Әтнә муниципаль районының «Комыргуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 11.11.2019 ел, № 117 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 10 статьяның 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга

**1.2.** 34 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.Җирлек советы керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм җирлек Советының бюджет турындагы карар проектын җирлек Советына керткәннән соң кабул ителгән карарларының нигезләмәләре Чираттагы финанс елында, агымдагы финанс елына һәм план чорына җирлек бюджетына үзгәрешләр керткәндә, агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә исәпкә алына.»

**1.3.** 27 статьяның 16 пунктындагы 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга

**1.4**. 15 статьяның 15 абзацын үз көчен югалткан дип танырга

**1.5**. 45 статьядагы 3 пунктта "түләү документлары" сүзләрен "казначылык түләүләрен башкару турында күрсәтмәләр (алга таба - күрсәтмә)" сүзләренә алмаштырырга, "түләү документлары" сүзләрен "күрсәтмә" сүзләренә алмаштырырга."

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында , Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча ) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында : (pravo.tatarstan.ru ) веб –адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Низамиев

СОВЕТ КОМЫРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КОМЫРГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ИНН 1610000733